ГЛАВА МУНАЙКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МОНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Тел.(85549): (85549) 3-58-09; e-mail: Mun.Men@tatar.ru, www:mendeleevsk.tatarstan.ru

# Авыл җирлеге башлыгы карары

№ 3 06.03.2025 ел

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге муниципаль
берәмлегенең җирдән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр
кертү проекты буенча
ачык тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 28 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына нигезләнеп, Монай авыл җирлеге Уставына, Менделеевск муниципаль районы "Монай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә ярашлы КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга

2. Ачык тыңлаулар урыны итеп Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Монай авылы, Төзүчеләр урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан Монай авыл мәдәният йорты бинасын билгеләргә. Узлыру вакыты һәм көне: 2025 елның 5 апреле 17.00 сәг.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

- Кириллов Руслан Михайлович- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгы;
- Әбүбакеров Илдар Шәвкат улы- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2 нче округ буенча муниципаль авыл җирлеге Советы депутаты;
- Садриева Зөлфия Мөнзир кызы – Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 4 нче округ буенча муниципаль авыл җирлеге Советы депутаты;

4. Түбәндәге адрес буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2025 елның 24 мартына кадәр кертелә: 423652, Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль

районы, Монай авылы, Ленин урамы, 54 йорт, авторның һәм аның адресын ФИА күрсәтеп һәм Mun.Men@tatar.ru электрон почтасына (эш көннәрендә 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр).

5. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 423652, Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Монай авылы, Ленин ур., 54 йорт, шәхсән яисә почта аша (конвертта “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Монай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм киңәшләр кертү ” дигән тамга белән) Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы карары белән расланган гавами тыңлауларны үткәрү тәртибе нигезендә 2025 елның 5 апреленә кадәр (тел.3-58-09) бирелә

6. Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге оештыру комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча билгеләнгән тәртип һәм әлеге карарда билгеләнгән сроклар нигезендә гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

7. Әлеге карарны Монай авылындагы махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatarstan.ru - «Монайка авыл җирлеге» бүлегендә, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында урнаштырырга.


8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге башлыгы Р.М.Кириллов

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге башлыгының
2025 елның 6 мартындагы 1 номерлы карарына
1 кушымта

## ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ МУНАЙКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

КАРТА ГРАНИЦ ЗОН С ОСОБЫМИ УСЛОВИЯМИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ ТЕРРИТОРИЙ



Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге башлыгының
2025 елның 6 мартындагы 1 номерлы карарына
2 кушымта

**ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ МУНАЙКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ.ТЕРРИТОРИАЛЬНЫЕ ЗОНЫ

